**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Олы Карагуҗа авылында**

**«9» нче декабрь 2019 ел** **№8**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Олы Карагуҗа авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Олы Карагуҗа авылында 2020 елда, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, 1 һәм 2 группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән кала, Олы Карагуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшүсмердән 500,00 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Олы Карагуҗа авылының Елга арты урамы юлын ремонтлау.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яшел Үзән муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Олы Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Карагуҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (мәдәният йорты бинасы), Олы Карагуҗа авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче** **М.Р. Минһаҗев**

**Олы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **М.Р. Минһаҗев**